**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Өркеш авыл җирлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**26 ноябрь 2021 ел** **№ 30**

**«Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Өркеш авылы гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2021 елның 7 декабрендә 13 сәгать 00 минутта Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Өркеш авылында балалар спорт мәйданчыгында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыены үткәрергә.

2. "Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Өркеш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Тау асты урамында юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю), проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелек;
- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)
- кышкы чорда территорияне кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, запас частьләр, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- Өркеш авылында артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу;;
- Тау асты ур., Өркеш авылы (2 скважина)буенча артезиан скважиналарыннан файдалануга лицензия алу өчен документлар пакетын һәм лаборатория тикшеренүләрен әзерләү чараларын тормышка ашыру . ;
- Тау асты ур., Өркеш авылларында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Өркеш авылында энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру.
- торак пунктны төзекләндерү (балалар мәйданчыгы тирәсендә коймалар алу һәм урнаштыру);
- Өркеш авылы урам-юл челтәрен һәм ишегалды юлларын ремонтлау-торгызу эшләре (проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
- проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»?

3. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Өркеш авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Өркеш авыл җирлеге башлыгы: А.Ш.Әгләмова